РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Исполнительный комитет
Козяково-Челнинского
сельского поселения
Рыбно-Слободского
муниципального района
Иванова ул., дом 26,
с.Козяково-Челны, 422668

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Балык Бистәсе
муниципаль районы
Казак-Чаллысы
авыл җирлеге
башкарма комитеты
Иванов урамы, 26 нчы йорт,
Казак-Чаллысы авылы , 422668

Тел.: (8-4361) 32-310 факс: (8-4361) 32-310, эл.адрес: Kcn.Rs@tatar.ru


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 11 октябре Казаклар Чаллысы авылы №30

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 2 номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Муниципаль норматив хокукый актны законнар белән тәңгәллеккә китерү максатларында, 2019 елның 26 июлендәге “Россия Федерациясе нотариат турында законнар Нигезенә һәм “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” Федераль законның 16.1 маддәсенә үзгәрешләр кертү хакында” 226-ФЗ номерлы Федераль законга, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы “Казаклар Чаллысы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 12 мартындагы “Үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламентын раслау турында” 2 номерлы карары белән расланган васыятьнамәләр һәм ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү Административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Карарның 1.5 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

“1.5.Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламенты (Кушымта №5).”;

1.2) 5 номерлы кушымтада:

а) исемне яңа редакциядә бәян итәргә:

“Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау буенча үзидарәлек хезмәте күрсәтү административ регламенты”;

б) 1.1, 3.3.1. пунктларында “васыятьнамәләрне таныклау буенча һәм” сүзләрен төшереп калдырырга;

в) 1.4 пунктның икенче абзацын төшереп калдырырга;

г) 2.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.1. Үзидарәлек хезмәтенең исеме | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау | “Россия Федерациясенең нотариат турында законнар Нигезе” (РФ ЮС тарафыннан расланган 11.02.1993 №4462-1) |

д) 2.3 һәм 2.4 пунктларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.3.Үзидарәлек хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсенн тасвирлау | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча нотариаль гамәлләр кылу. Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәне таныклау буенча нотариаль гамәлләр кылуны кире кагу. | |
| 2.4. Үзидарәлек хезмәте күрсәтү срогы | Күчемсез мөлкәт белән файдалануга ышанычнамәләрдән гайре ышанычнамәләрне таныклау мөрәҗәгать иткән мизгелдән соң бер көн эчендә гамәлгә ашырыла | |

е) 3.4.1. пунктының тугызынчы абзацында “васыятьнамәләрне нотариаль таныклау һәм” сүзләрен төшереп калдырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Казаклар Чаллысы авыл җирлегенең түбәндәге адрес буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга: Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе районы, Иванаево авылы, Калинин урамы,18 йорт; Бирдебәк авылы, Мәктәп урамы, 4 йорт;Үри Чаллысы авылы, Гаврилов урамы, 24 йорт һәм Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы”нда.

4. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне үземнең җаваплылыкта калдырам.

Татарстан Республикасы
Балык Бистәсе муниципаль районы
Казаклар Чаллысы
авыл җирлеге башлыгы И.С.Ананьев